# A NEW BOOK – "TATAR-FINNISH DICTONARY" (ARTO MOISIO, OKAN DAHER "TATAARILAIS-SUOMALAINEN SANAKIRJA. – TATARÇA-FINÇӒSÜZLEK" – HELSINKI, 2016, 418 p.)

**Mustafa Oner,**
the Ege University,
Bornova, Izmir, 34100, Turkey,
mustafa.oner@ege.edu.tr.

**Alfiya Shavketovna Yusupova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlevskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
alyusupova@yandex.ru.

The review describes a Tatar-Finnish dictionary, containing 11,000 words and phrases of the modern Tatar language, it includes common abbreviations and some geographic names. The dictionary covers the most common vocabulary of various areas of the language - from colloquial words to journalistic vocabulary and popular science terminology. In the appendixes a comparative analysis of the Tatar alphabets used in Finland and in the Republic of Tatarstan is given, and the lexicon characteristic only of the Finnish Tatars is systematized. The dictionary is intended for a wide range of readers - from experts in the Tatar language to people learning Tatar and Finnish.

**Key words**: Tatar language, Finnish language, lexicography, Finnish-Tatar dictionary, Arto Moisio and Okan Daher. Tatar-Finnish.

The history of Tatar lexicography has a long tradition. This early emergence of Tatar lexicography was facilitated by the fact that the Tatars had political, commercial, economic, and cultural relations with other peoples. As our people settled between Europe and Asia, the Tatar language became an intermediary between other Turkic languages.

Linguistic dictionaries play an important social and cultural role in people's life. On the one hand, they help the representatives of different nationalities to understand each other and solve different common problems, on the other hand, dictionaries preserve people's knowledge of a specific period of time. Hundreds of bilingual dictionaries have been compiled for centuries. Words have been presented and explained in different ways. Certain dictionaries are of great help for their users, however, others are not helpful enough. Bilingual or translation dictionaries are an important source for learning languages. Dictionaries area result of their author-compliers' research work, as the authors focus on linguistic features, the usage of lexical units, and their derivatives, providing variants of translation and giving necessary explanations. They explore language, trying to solve different linguistic issues.

Among the dictionaries published in recent years, one of the most interesting and worth noticing is the "Tatar-Finnish Dictionary". This book was compiled by the Department of Volga Region Language Studies at the University of Turku, it was added to the list of publications of the Finno-Ugric Association and financed by "Kone" foundation. The head of the project is Sirkka Saarinen, the project executive is Yorma Luutonen, and the authors of the dictionary are Arto Moisio and Okan Daher. A few more words about one of the authors: Okan Gomarovich Daher is our fellow-countryman. He is a lecturer of the Tatar language and culture in Helsinki University, an honourable president of the Islamic Tatar society in Finland. He is the one who has been uniting the Tatars in Finland for many years.

This dictionary, published in Finland in 2016, consists of 418 pages, and includes 11 thousand entries. Lexical units are given in alphabetical order, with a preface in Finnish and Tatar, both Cyrillic and Latin scripts are used. The Tatar alphabet and specific words and word combinations, used by the Finnish Tatars, are given in the supplement.

The dictionary is based on the main principles of lexicography, in other words, most of information is given in brief, in small quantities. At the same time, this dictionary meets many requirements of a user: Finnish interpretations of Tatar words, explanations of different meanings, and usage areas. One should have specific knowledge and linguistic instinct to compile such dictionaries. The main thing is to provide a correct equivalent to a word in the other language.

The structure of the dictionary is standard and simple as far as parts of the dictionary accepted in lexicography and structure principles go. The megastructure of the "Tatar-Finnish Dictionary" has the following pattern: Alkusanat – preface– kereş, Sana-artikkelin rakenne – dictionary structure – süzlek mäkaläsenen tözeleşe, Lyhenteet – abbreviations – kiskartmalar. The main part of the dictionary is its corpus. The Tatar language comes first here. According to the theory of lexigraphy, if the first language is Tatar, the dictionary is intended for active users of the Tatar language. Those who learn Tatar can use this dictionary while reading texts, translating them into Tatar, or while learning Tatar words, and those who speak Tatar can use this dictionary to translate Tatar texts into the Finnish language. The corpus of 11 thousand words is presented in different ways. The book presents the meanings of a word in a different way. Each word is given in 3 forms: a Tatar word in Cyrillic script is given in bold type, its variation in Latin script is given in italics and its Finnish equivalent follows. For example, **azhagan** (summer lightning) *acagan* elosalama [1, p. 7], **zhimlek** (crib) *cimlek* rehukaukalo [1, p. 88], etc. The dictionary compilers are scrupulous about each item. Along with the interpretation of the word, its usage is given: **mai** (butter) *may* I 1. Voi. **Mai savyty** (butter dish) voiastia, voirasia. **mai yazarga/atlarga** (turn cream into butter) kirnuta voita. **Mai kap!** (keep silent) Hijiaa!, suu kiinni! **Mai kebek yagyla** (spread like butter) olla myelin kielin, mielistellä, **mae chykmas** (not exuding oil) ei tule [mistään], **maenad chydyi almyi** (be naughty) oikutella, temppuillfa, **maida yozarga** (swim in oil) elää kissanpäiviä, **mai zhiteshteru zavody** (dairy factory) meijeri. 2. rasva, tali,ihra,läski,silava. **mai bizlare** (oil glands) talirauhaset. **balyk mae** (fish-oil) kalaöljy, traani. 3. Salva, voide, rasva. 4. (kuv.) kerosiini, bensiini [1, p. 192]. There are indications given in abbreviations in brackets next to some words. They clarify the usage area of an item. For example, **aiduk** (welcome) *äydük* (puh.) olkaa hyvä, tervetuloa [1, p. 27], **aye** (yes) *äye, eye* 1. (part.) kyllä, tietysti [1, p. 27]; **kugan** (black thorn) *kügän* II (bot.) oratuomi, oratuomen marja [1, p. 164]. As is seen from the examples, there is a label, showing if it is a simple lexical unit, particle, or botanical term.

The dictionary contains words actively used in the Tatar language. It is based on the Tatar-Russian dictionaries published in different years. There are units with Turkic-Tatar, Russian-European, Arabic and Farsi origins. Many words denote geographical nominations: **Aziya** (Asia) *Aziya* Aasia. **Urta Aziya** (Middle Asia) Keski Aasia [1, p. 7], **Misyr** (Egypt) *Misir* Egypti [1, p. 205], **Mazharstan** (Hungary) *Macarstan* Unkari [1, p. 191], *Almanya* Germany [1, p. 415], *Filistin* Israel [1, p. 416], *Sibirya* Siberia [1, p. 417], etc.

Two supplements are given at the end of the dictionary. The first supplement compares the Tatar literary alphabet with the alphabet used by the Tatars living in Finland, showing the similarity of letters and explaining specific characteristics.

The second supplement contains lexical units which the Finnish Tatars use: 500 words in total. They differ from the Tatar literary language phonetically. For example, there are words without the uvular sound [ғ] ([g]): *alim* galim (scholar) [1, p. 415], *afu* gafu (sorry) [1, p. 415], *adi* gadi (simple) [1, p. 415], *adel* gadel (fair) [1, p. 415], *omer* gomer (life) [1, p. 417 ], *saat* sagat (clock) [1, p. 417], etc. We can also see such interesting lexical units as *bazarkön* **yakshambe** (Sunday) [1, p. 415], *bähet böcäge* **kamka** (silk) [415], *oçkiçbikä* stewardess [1, p. 418], *dolmakaläm* fountain pen [1, p. 416], *kravat*tie [1, p. 1417], *gömrük* customs [1, p. 416] and others.

According to its macrostructure, this is an alphabetically compiled dictionary. The alphabetical order holds good for the second and third letters of the word. Verbs are given as infinitives.

Analyzing this dictionary, we arrived at the conclusion that the authors managed to preserve characteristic features of both nations and both languages, showing their phonetic and grammatical distinctions. The fact that the Tatar language was taken as the first language and the wealth of interesting lexical units, contained in the dictionary, prove that our language is needed and used in foreign countries.

This dictionary continues the series of dictionaries, i.e. Tatar-German [2], Tatar-English [3], and Tatar-Turkic, recently published abroad, which introduce our language to other nations.

**References**

Dawletschin, T., Dawletschin, I., Tezcan, S. (1989). *Tatarisch-Deutsches Worterbuch* [Tatar-German Dictionary]. 380 p. Wiesbaden, Harrassowitz. (In Tatar, in German)

Moisio, A., Daher, O. (2016). *Tataarilais-suomalainen sanakirja-татарча-финча сүзлек – tatarça-finçä süzlek* [Tatar-Finnish Dictionary]. 418 p. Helsınkı. (In Tatar, in Finnish)

Mustafa, Ö. (2015). *Kazan Tatar Türkçesi Sözlüğü* [Kazan Tatar-Turkish Dictionary]. 603p. Ankara, Türk Dil Kurumu Yayınları 2.baskı. (In Tatar, inTurkish)

Shakhmayev, S. (1994). *Tatar-English, English-Tatar Dictionary*. 200 p. New-York. (In Tatar, in English)

# ЯҢА КИТАП – «ТАТАРЧА-ФИНЧА СҮЗЛЕК» (ARTO MOISIO, OKAN DAHER «TATAARILAIS-SUOMALAINEN SANAKIRJA. ТАТАРЧА-ФИНЧА СҮЗЛЕК. – TATARÇA-FINÇӒ SÜZLEK» - HELSINKI, 2016, 418 S.)

**Мостафа Өнәр,**
Эгей университеты,
Төркия, 34100, Измир ш., Борнова,
mustafa.oner@ege.edu.tr.

**Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
alyusupova@yandex.ru.

Бәяләмәдә хәзерге татар әдәби теленең 11000 сүз һәм сүзтезмәсен, шул исәптән гомумкулланылыштагы кыскартылма сүзләр, географик атамаларны үз эченә алган татарча-финча сүзлеккә тасвирлама бирелә. Сүзлектә телнең төрле өлкәләренә караган аеруча киң таралыш алган берәмлекләрне күзәтергә мөмкин: сөйләм телендә кулланыла торган сүзләр, публицистик лексика, фәнни-популяр терминология. Кушымтада Финляндиядә һәм Татарстан Республикасында гамәлдә булган татар алфавитларына чагыштырма анализ ясала, шулай ук фин татарларында гына очрый торган лексик берәмлекләр системалаштырыла. Сүзлек киң катлам укучылар – татар теле белгечләре, татар һәм фин телләрен өйрәнүчеләр – игътибарына тәкъдим ителә.

**Төп төшенчәләр:** татар теле, фин теле, лексикография, татарча-финча сүзлек, Арто Мойсио, Окан Дахер.

Татар теленең сүзлекчелек тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Татар халкының башка халыклар белән иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни, сәүдә, көнкүреш бәйләнешләре, халкыбызның Европа һәм Азия чигендә урнашуы, татар теленең башка төрки халыклар белән бәйләнештә арадашчы булуы татар лексикографиясенең шактый иртә барлыкка килүенә сәбәп була.

Лингвистик сүзлекләр халык тормышында бик мөһим иҗтимагый һәм мәдәни функция башкара. Берьяктан, алар, төрле милләт вәкилләренә бер-берсен яхшы аңлап, төрле уртак мәсьәләләр чишәргә ярдәм итсә, икенче яктан, сүзлекләр үзләрендә теге яки бу халыкның шул чордагы төп белем нигезен туплап тора. Гасырлар дәвамында йөзләрчә икетелле сүзлекләр төзелгән. Аларда сүзләр төрлечә бирелгән һәм төрлечә аңлатылган. Кайбер сүзлекләр бик уңышлы килеп чыккан, ә кайберләре кулланучы өчен алай ук җайлы булмаган. Икетелле, ягъни тәрҗемәи сүзлекләр тел өйрәнү өчен иң мөһим чыганак булып торалар. Шул ук вакытта, сүзлек аны төзүче авторның лингвистик эзләнүләре нәтиҗәсе итеп тә карала, чөнки автор сүзләрне тәрҗемә иткәндә, төрле аңлатмалар биргәндә, нәзари тел белеменә, сүзләрнең кулланылышына, ясалышына да игътибар итә. Теге яки бу телнең четерекле яклары белән очраша, аларны уңай хәл итәргә тырыша.

Соңгы елларда чыккан сүзлекләрдән иң кызыклысы һәм игътибарны җәлеп итә торганы, мөгаен, «Татарча-финча сүзлек»тер. Бу хезмәт Турку университетының Идел буе телләрен өйрәнү бүлеге тарафыннан төзелгән, Фин-угор җәмгыяте басмалары исемлегенә кертелгән, «Коне» фонды тарафыннан финансланган. Проектның җитәкчесе – Сиркка Сааринен, эшне оештыручы – Йорма Луутонен, сүзлек авторлары – Арто Мойсио һәм Окан Дахер. Авторларның берсе турында аерым искә алу кирәктер. Окан Гомәр улы Дахер – безнең милләттәшебез. Ул – Хельсинки университетының татар теле һәм мәдәнияте дәресләре лекторы, Финляндия ислам татар җәмгыятенең

шәрәфле президенты, Финляндиядә яшәүче татарларны озак еллар туплап, оештырып торучы танылган шәхес.

2016 елда Финляндиядә Хельсинки шәһәрендә басылган бу сүзлек 418 биттән тора, үз эченә 11 мең берәмлекне берләштерә. Лексик берәмлекләр татар алфавиты тәртибендә урнаштырылган, кереш сүз фин һәм татар телләрендә кирилл һәм латин графикасында бирелгән. Татар алфавиты, Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез сөйләмендә куллана торган үзенчәлекле лексика кушымта итеп тәкъдим ителгән.

Сүзлек лексикографиянең төп принцибына, ягъни күп мәгълүматны кыска итеп, аз күләмдә бирүгә нигезләнә. Шул ук вакытта әлеге сүзлек кулланучының бик күп мәнфәгатьләрен канәгатьләндерә: анда татар сүзенең фин теленә тәрҗемәсе бирелә, мәгънә төрләре күрсәтелә, кулланылыш даирәсе чагылдырыла. Бу төр хезмәтләрне төзү махсус белем һәм лингвистик тоемлау таләп итә. Шулай ук сүзнең икенче телдәге дөрес эквивалентын табу да төп шарт булып санала.

Сүзлекнең стуктурасы гадәти һәм гади. Сүзлек структурасы лексикография фәнендә сүзлекнең өлешләренә һәм төзелеш принципларына мөнәсәбәттә карала. Мегаструктура, ягъни кысалы структура – сүзлекнең бүлекләре буенча «Татарча-финча сүзлек»тә түбәндәге тәртип күзәтелә: Alkusanat – кереш – kereş, Sana-artikkelin rakenne – сүзлек мәкаләсенең төзелеше – süzlek mäkaläsenen tözeleşe, Lyhenteet – кыскартмалар – kiskartmalar өлешләре аерып күрсәтелә. Сүзлекнең төп өлеше – корпус. Сүзлекчелек теориясе буенча, беренче итеп кайсы тел куелса, сүзлек шул телне кулланучыларга адресланган санала Монда татар теле алына. Бу сүзлекне татар телен өйрәнүчеләр текстлар укыганда, текстларны татар теленә тәрҗемә иткәндә, татар сүзләрен ятлаганда файдалана алалар, ә татар телен белүчеләр өчен бу сүзлек татар текстларын фин теленә тәрҗемә иткәндә беренче ярдәмче була ала. 11 мең сүзне берләштергән корпуста сүзләр төрлечә чагылыш таба. Бу сүзлектәге һәр сүзнең мәгънә сыйдырышлылыгы, төрле үзенчәлекләре белән бәйле. Һәр сүз өч шәкелдә бирелә: кирилл графикасында калын хәрефләр белән татар сүзе, курсив белән аның латин графикасындагы язылышы һәм фин эквиваленты. Мәсәлән, **аҗаган** *acagan* elosalama [1, б. 7], **җимлек** *cimlek* rehukaukalo [1, б. 88] һ. б. Сүзлек төзүчеләр һәр берәмлеккә җитди якын килгәннәр. Сүзнең тәрҗемәсе белән бергә, аның кулланылышы да күрсәтелә: **май** *may* I 1. Voi. **май савыты** voiastia, voirasia. **май язарга/атларга** kirnuta voita. **Май кап!** Hijiaa!, suu kiinni! **Май кебек ягыла** olla myelin kielin, mielistellä. **мае чыкмас** ei tule [mistään], **маенда чыдый алмый** oikutella, tempрuillfa. **майда йөзәргә** elää kissanpäiviä, май җитештерү заводы meijeri. 2. rasva, tali,ihra,läski,silava. **май бизләре** talirauhaset. **балык мае** kalaöljy, traani. 3. Salva, voide, rasva. 4. (kuv.) kerosiini, bensiini [1, б. 192]. Кайбер сүзләр янына җәяләр эчендә кыскартылмалар белән бирелгән индекслар бар. Алар теге яки бу берәмлекнең кулланылыш даирәсен ачыклый. Мәсәлән, **әйдүк** *äydük* (puh.) olkaa hyvä, tervetuloa [1, б. 27], **әйе** *äye, eye* 1. (part.) kyllä, tietysti [1, б. 27]; **күгән** *kügän* II (bot.) oratuomi, oratuomen marja [1, б. 164]. Мисаллардан күренгәнчә, сүзләр янына аларның гади сөйләм берәмлеге, кисәкчә, ботаник термин булулары күрсәтелгән.

Сүзлектә татар телендә актив кулланылышта булган сүзләр теркәлгән. Хезмәт төрле чорларда дөнья күргән татарча – русча сүзлекләргә нигезләнеп эшләнгән. Сүзләр арасында төрки-татар чыгышлы берәмлекләр белән беррәттән рус-европа алынмалары да шактый урын алган, гарәп-фарсы сүзләре дә үз урыннарын саклаганнар. Сүзлек мәкаләләре арасында географик атамаларга караганнары да очрый: **Азия** *Aziya* Aasia. **Урта Азия** Keski Aasia [1, б. 7], **Мисыр** *Misir* Egypti [1, б. 205], **Маҗарстан** *Macarstan* Unkari [1, б. 191], **Германия** *Almanya* [1, б. 415], **Фәлистин** *Filistin* [1, б. 416], **Себер** *Sibirya* [1, б. 417] һ.б.

Сүзлек ахырында ике кушымта бирелә. Беренче кушымтада авторлар татар әдәби теле алфавитын Финляндиядә яшәүче татарлар кулланган алфавит белән чагыштырып бирәләр, аваз тәңгәллекләрен күрсәтәләр. үзенчәлекле билгеләрне аңлаталар.

Икенче кушымта Финляндиядәге татарлар сөйләменә хас лексиканы берләштерә. Анда барлыгы 500 сүз теркәлгән. Алар татар әдәби теленнән, нигездә, фонетик яктан аерыла. Мәсәлән, увуляр [ғ] авазы төшеп калган сүзләр урын ала: *alim* галим [1, б. 415], *afu* гафу [1, б. 415], *adi* гади [1, б. 415], *adel* гадел [1, б. 415], *omer* гомер [1, б. 417], *saat* сәгать [1, б. 417] һ.б. Шулай ук *bazarkön* **якшәмбе** [1, б. 415], *bähet böcäge* **камка** [1, б. 415], *oçkiçbikä* **стюардесса** [1, б. 418], *dolmakaläm* авторучка [1, б. 416], *kravat* галстук [1, б. 147], *gömrük* таможня [1, б.

416] һ.б. шундый кызыклы лексик берәмлекләрне дә очратабыз.

Макроструктура ягыннан караганда, бу – алфавит буенча төзелгән сүзлек. Алфавит тәртибе сүзнең икенче, өченче хәрефләрендә дә саклана. Фигыльләр инфинитив формасында тәкъдим ителә.

Бу сүзлекне өйрәнеп, түбәндәге нәтиҗәгә килдек. Авторлар хезмәттә ике халыкның, ике телнең үзенчәлекләрен сакларга, фонетик һәм грамматик якларын чагылдырырга тырышканнар. Татар теленең беренче тел итеп алынуы, сүзлектә бик кызыклы лексик байлык туплануы телебезнең чит илләрдә кирәклеге, мөһимлеге турында сөйли.

Бу сүзлек соңгы дәвердә ерак чит илләрдә чыккан, телебезне башка мохиттә, чит мәмләкәтләрдә таныткан татарча-алманча [2], татарча-инглизчә [3], татарча-төрекчә сүзлекләрнең матур дәвамы булып тора.

**Әдәбият**


Moisio A., Daher O. Tataarilais-suomalainen sanakirja. Татарча-финча сүзлек. – Tatarça-finçä süzlek. – Helsınkı, 2016. – 418 s.

Dawletschin T., Dawletschin I., Tezcan S. Tatarisch-Deutsches Worterbuch. – Wiesbaden, Harrassowitz, 1989. – 365 s.

Shakhmayev S. Tatar-english, english-tatar dictionary. – Нью-Йорк, 1994. – 200 s.

Mustafa Ö. Kazan Tatar Türkçesi Sözlüğü. – Ankara, Türk Dil Kurumu Yayınları 2.baskı , 2015. – 603 s.


---

# НОВАЯ КНИГА – «ТАТАРСКО-ФИНСКИЙ СЛОВАРЬ» (ARTO MOISIO, OKAN DAHER «TATAARILAIS-SUOMALAINEN SANAKIRJA. ТАТАРЧА-ФИНЧА СҮЗЛЕК. – TATARÇA-FINÇÄ SÜZLEK». HELSINKI, 2016, 418 S.)


**Мостафа Онер,**
Эгейский университет,
Турция, 34100, Измир ш., Борнова,
mustafa.oner@ege.edu.tr.

**Альфия Шавкетовна Юсупова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
alyusupova@yandex.ru.



В рецензии дана оценка татарско-финскому словарю, содержащему 11000 слов и словосочетаний современного татарского языка, включая общеупотребительные аббревиатуры и некоторые географические названия. Словарь охватывает наиболее распространенную лексику различных сфер языка – от разговорных слов до публицистической лексики и научно-популярной терминологии. В приложениях дается сравнительно-сопоставительный анализ татарских алфавитов, используемых в Финляндии и в Республике Татарстан, а также систематизирована лексика, характерная только для финских татар. Словарь предназначен для широкого круга читателей – от специалистов по татарскому языку до лиц, изучающих татарский и финский языки.



**Ключевые слова:** татарский язык, финский язык, лексикография, финско-татарский словарь, Арто Мойсио, Окан Дахер, татарско-финский.